| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

11.12.2014 Казан ш. № 2827-р

**Татарстан Республикасы Чистай, Түбән Кама (өлешчә) муниципаль районнары территориясендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләрнең) саклык зонасы чикләрен раслау турында**

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56 статьясына, «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау турында карарлар кабул итү тәртибен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү турында” 30.04.2014 № 288 карарына туры китереп һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате һәм газ бүлү челтәрләренә милек хокукын раслаучы документлар нигезендә, һәм «Земля» республика кадастр үзәге» ААҖ (алга таба – «Земля» РКҮ ААҖ) башкарган документациягә туры китереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы) КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләрнең) саклык зонасы чикләрен расларга:

1.1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясендә урнаштырылган, 765,1012 км озынлыктагы, гомуми мәйданы 3,11691671 кв.км.лы (3 116 916,71 кв.м) территорияне тәшкил иткән ЭПУ

«Чистопольгаз»ның әлеге карарга 1 нче кушымтада күрсәтелгән инвентарь номерлы газ бүлгеч челтәрләренең саклык зонасы чикләрен 2014 елның 3 августыннан 2014 елның 10 сентябре аралыгында «Земля» РКҮ ААҖ башкарган һәм 2014 елның 1 октябрендә «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ белән килештерелгән җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталары координаталары исемлегенә нигезләнеп расларга.

1.2. Татарстан Республикасы Түбән Каам муниципаль районы (өлешчә) территориясендә урнаштырылган, 5,13921 км озынлыктагы, гомуми мәйданы 20 604,43 кв.м территорияне тәшкил иткән ЭПУ « Чистопольгаз»ның әлеге карарга 1 нче кушымтада күрсәтелгән инвентарь номерлы газ бүлгеч челтәрләренең саклык зонасы чикләрен 2014 елның 5 августыннан 2014 елның 10 сентябре аралыгында «Земля» РКҮ ААҖ башкарган һәм 2014 елның 1 октябрендә «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ белән килештерелгән җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталары координаталары исемлегенә нигезләнеп расларга.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән газ бүлү челтәрләре объектының саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә газ бүлү челтәрен эксплуатацияләү срогына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖга тәкъдим итәргә:

1) газ бүлгеч челтәрләрнең саклау зоналары турында белешмәне Күчемсез милек дәүләт кадастрына кертү чараларын күрергә;

2) әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән газүткәргечләрнең саклау зоналарына кергән әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә йөкләүләрне Күчемсез милек хокуклары һәм аның белән алыш-биреш итү бердәм дәүләт реестрында регистрацияләү чараларын күрергә;

3) әлеге карар кабул ителүгә 10 көн эчендә аны Татарстан Республикасы буенча “Росреестр федераль кадастр палатасы” филиалына юлларга, шулай ук, әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән газүткәргечләрнең саклау зоналары җир төзелеше объектлары карталарын (план) XML-схемалар кулланып төзелгән һәм бирелгән мәгълүматның укылышын һәм контролен тәэмин итүче XML форматындагы файллар рәвешендә, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән газүткәргечләрнең саклау зоналары турында һәм әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә булган

чикләүләрне Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрына кертү өчен хокукларны регистрацияләү органына юлларга.

4. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны җир ресурслары идарәсе башлыгы Г.Э.Миндубаевка йөкләргә.

**Министр** **А.К.Хамаев**